РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
08.04.2026

КАРАР
№391-п

Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 нче елның 22 ноябрендәге №1188-п номерлы «Россия Федерациясе кораллы көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы «Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак (вафат) булган гражданнарның гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында»гы карарына (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) ярашлы рәвештә, Саба муниципаль районы Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 22 ноябрендәге №1188-п «Россия Федерациясе гражданнарының мобилизация буенча Россия Федерациясе Кораллы көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гаиләләренә өстәмә ярдәм чаралары турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылганнар, Россия Федерациясе Милли гвардиядә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр һәм затлар, Татарстан Республикасында оештырылган «Алга», «Тимер» һәм «Батыр» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле рәвештә үтәүче гражданнар, махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре, шулай ук югарыда күрсәтелгән категориядәге махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) ярдәмнең түбәндәге өстәмә чараларын билгеләргә:

- Саба муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын

гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларында балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләүдән тулысынча азат итәргә

- Саба муниципаль районы мәгариф оешмаларында мәктәп туклануы өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләүдән тулысынча азат итәргә;

- мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Саба муниципаль районының муниципаль мәгариф оешмаларына чираттан тыш керү хокукын бирергә.».

6. Әлеге карарны рәсми рәвештә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» МКУ начальнигы Шакиров И.Ф.ка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитет
Җитәкчесе М.Р. Кәримов